СОВЕТ
НАДЕЖДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ НАДЕЖДИНО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.05.2025 Надеждино ав. № 98

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең коррупциячел хокук бозуларны кылган өчен Надеждино авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турында» 2013 елның 01 февралендәге 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлеге Советы КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең коррупциячел хокук бозуларны кылган өчен Надеждино авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турында» 2013 елның 01 февралендәге 7 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4 пунктының икенче абзацында «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен төшерергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Надеждино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге Башлыгы Е.В.Савельева